# Хәкимова Сылубикә
# Хамидулла кызы

**(6.12.1907 - 6.03.1983)**



Хәкимова Сылубикә Хамидулла кызы Кызыл Мишә авылында 1907 елның 6 декаберендә туа. Алан-Елга авылы егете Бәдыйкка кияүгә чыга. Гомере буе басуда кәкре урак белән ашлык ура, чүп утый, көлтә бәйли. 3 балалары туа: Йөзлебикә, Хаҗиәхмәт, Галиәхмәт.

Тракторчылар басуда эшли башлагач, аш пешерә, көндәлек ипи пешерә. 1967 елның 9 декабрендә пенсиягә чыга, 12 сум пенсия алган. Эшләгән өчен 3 сум 5 тиен күләмендә акча түләгәннәр. Бик кызу, итагатьле, шул кадәр әйбәт хатын булган. (әнкәй сөйләгәннәрдән)

1983 елның 6 мартында вафат булган. Үләр алдыннан бик күп коймак ашаган. Соңгы ризыгы шул булган. Алан –Елга зиратына җирләнелә.





ТАССР
(область, край, АССР)
(районный, городской отдел социального обеспечения)
(наименование колхоза)

УДОСТОВЕРЕНИЕ №762497

Фамилия Хамидуллина
(получателя)
Имя Солубика
Отчество Хамидулловна
Год рождения 1907 6/XII
Вид пенсии по старости

(образец подписи получателя)

Пенсия назначена по старости, по ........ группе инвалидности, по случаю потери кормильца на........ членов семьи в соответствии с Законом о пенсиях и пособиях членам колхозов и п. 8.11 Положения о порядке назначения и выплаты пенсий членам колхозов из среднемесячного заработка 3 руб. 05 коп.

В размере Двенадцать
(прописью)

Пенсия назначена с 9/XII 1967 г.
по пожизненно 19...... г.
Удостоверение выдано 30/XII 1967 г.

Зав. отделом
М. П.
Ст. бухгалтер

Мирзегалямова Гөлсинә кульязмасыннан.

18.04.2016

Д.Б.Рамазанова “Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре”, Казан, 2010

Китап 2004-2013 елларга Татарстан Республикасы дәњләт телләрен џәм Татарстан Республикасында бешка телләрне саклау, љйрәнњ џәм њстерњ буенча Татарстан Республикасы Дәњләт программасын њтәњ максатында нәшер ителә.

Сөйләүче: Хәкимова Сылубикә, 68 яшь. Татарстанның

Саба районы, Алан Елга (Яңа Шекше) авылы. Эксп., 1973 ел.

Дүрт бәбәйтәкле зәңгәр дубейни күлмәгем бар ийе инде, бер бәбәйтәк салғанийығ инде, үзе аның ниләре (изүләре һ.б. җирләре) хәзерге шикелле түгел инде, туп-туры, пырастуй инде ул шушылай, менә шушылай пырастуй бүтән бер (нәрсә) йуғ ийе тулқышты. Озон қысалы ул име, дүрт балайтәк салған ийе аңа, йақасы бар. Йақасыз күлмәк кимәдем үз ғөмөремә дә. Болай әйләндермә йақа түгел. Хәзер чықты ул әйләндермә. Турыға ғына йақа, әнә синең күлмәқнең, күфәйкенең йақасы бар бит, менә шуның шикелле туры ғына йақайы. (Дубейни) үзеннән чыққан чуптарлы, үзеннән чыққан ийе чуптары. Тулкы ул төрлөчә түгел, бер үзе җете зәңгәр ийе, әй ақсыл зәңгәр ийе әйеме, чуптар үзеннән чыға. Сәтин түгел ул, сәтин айырым.

Менә хәзер димче килә инде име, сорый инде. Менә ди, мин сиңа, ди, димчегә килдем, ди, қызыңны миңа бирәсең, ди инде име. Инде бер килә, ике килә, аннары өчөнче килүендә мәһәргә әйберләр төйнәп килә хәдер. Әнә шул, менә шул инде қыз җағыннан да бирәләр инде, ир җағына да әйбер төйнәп килә инде, бүләкләр апкилә инде бераз, димче ышанып килеп китә хәдер, име димче килеп киткән чағында димчегә биреп җибәрәләр хәдер ақлашқачыннан әйберләр, намазлық, сөлгө, бер-ике намазлықмы, сөлгө, бүтәнчә бүләк-салақ жуқ, сөлге, ашаулық бирәләр, килешеп киткән чағында име. Хәдер ақлашып китте бит инде. Димче килеп китт, е, инде хәдер ақлашып, шуннан суң ул җәңәдән килә туй билгесе қуйарға, ничәсенә туй килә. Аннары инде туйға киләләр, ничә кеше килә, ничә пар кеше килә. Монда қыз җағында әзерләнәләр. Элек қыз җағына барамы туйға, элек қызда була. Безнең тәтәне апкиттеләр, қыз җағында булды туй. Безнең бабайларда булды туй. Бәк шәб итеп туй йасадылар инде хәдер. Хәдер кийәү киләсе бар бит хәзер. (Туйға) парлап-парлап, ат белә киләләр пулный қазлар пешереп, паштитлар пешереп, бүләг алып килә инде туйға. Менә безгә дә төштөләр, күлмәкләр алып төштөләр. Туй киткәннән суң, хәзер кийәү килә инде қыз җанына қунарға, хәзер инде кийәү киләсе бар, кийәүгә урын җәеп қуйдылар алдан. Хәзер мин тигезле кеше баласы бит инде, әтинең төп жортонда бит инде бу, тигезле кеше баласы дип, барыбер тормады бичарақайым, апкерде дә, мине түшәккә тәгәрәттеләр, тигезле кеше баласын тәгәрәтәләр йәнәсе, кийәү йатасы түшәк, тигезле кеше баласын (тәгәрәтәләр), йәнә тигез ғљмљр итсеннәр. Өч йәшлег ийем шуңа күрә белә торғанмындыр, аннары кийәү килгәченнән утырып бер самаwыр чәй эчә дә, қыз белә җегет шул көйөнчә қала инде.

Аннары иртә беләнгә мунча йағабыз, қоймақ пешә. Киленне аны менә бер қат кийәүләп җөрдө дә әүвәле, бер ай җөриме кийәү, атна кич сайын килә, бер кич қунып, ике кич қунып китә инде. Қайсы килгәндә икене қуна, атна кич қуна, җомға көннө қуна да шимбә қайтып китә инде. Аннары инде қайтып киткәченнән аннан бер ай, аймы кийәүли дә алмаға килә зурлап, кийәү алмаға килгәченнән, төйәделәр малай безнең Бәдриҗамал абыстайға, қомған да қалмады, көйәнтә дә қалмады, чиләк тә қалмады. Күб итеп әйберне төйәп озата киттеләр, сондоқ булмыйча, әwәле булды инде ул, хәдер дә бар әле ул сондоқ. Сондоққамы? Хәзер челтәр име, менә мин үзем дә унике ашаулығ әлдем өләңгә урнына. Унике ашаулық түргә генә, менә эстинәгә элеп чыктым, сөлгө почмақ сайын парлап. Теге әүвәле чүпләмне сөлгөләр, қып-қызыл башлы. Берне озонны эләсең, икенчесен, қысқарағын, өстөнә элеп қуйабыз сөлгөне, аңа бәк күп кирәг инде әйбер, гел қул белән сукқан бит аны, үзем суктым. Киленне үз йағындағы йақын қәрендәшләре озата бара, қодалар, қодачалар килә. Қодалар-қодачалар килә бездә. Алар озата киләләр дә әнә шул килеп, ашап-эчеп, йәш киленгә әпкилгән әйберсе белә өйне киендереп бергә-бергә, аннары қайтып китәләр. Киленне әwәле шул күпчек салып төшерә торғаннар ийе. Арбадан төшүгә, тарантастан төшүгә, айағ астына күпчек қуйа торғаннар ийе. Йәнәсе йомошақ сүзле була. Қергәч килеп күрешә инде. Пирwай башта бийем белән күрешә, бийата белә күрешү булмады ул элек. Аннары қаршы алучылар күп бит инде, қодачалар, кодағыйлар дигән шикелле. Шулай кодағыйлар була бит, шулар күрешеп, қаршылаб алып кертеб утырталар инде, безнең заманда әйбер қаптырмадылар.

**Киндер турында**. Ин әwәле киндерне чәчтек. Ин әwәле аның өстөнә үсеп чықты баса. Баса ди торғаннар ийе, бер төрлө песи башлы ғына, песи қойрығы шикелле нәстә (баса) чықты аның өстөнә. Аны җийыб алдық. Җыйыб алдық та җәйдек. Җәйгәченнән күпме йатты, өч атна йатты микән ул җир өстөндә, аннары җийыб алдық. Җыйыб алып күбәләп қуйып киптердек тә мунчаға күтәрдек тә талқыдық. Талқыйсы бар аны, басаны. Талқыдық та, аннары һәйбәтләп талқығаннан суң көйләгә салып төйдөк. Аннары җегерләгәченнән шуны һәйбәтләп киндер итеп суктық, хәзер киндердән. Киндерне җийыб алып суктық хәзер, көйләгә салып төйдөк ансын тағы, аны суға салдық. Басаны җиргә җәйдек, ә киндерне суға салып булдырыб алдық, сөйәген. Аннан судан алғачыннан, киптердек тә талқыдығ инде аны мучаға күтәреб эме. Күтәреб алдық та хәдер инде күтәреп алып талқып сүс иткәннән соң җегерлибез инде, киләб ағачына сарабыз, ничә басма была, бүрәнә буйына тартабыз, алтышар бүрәнә, бишәр бүрәнә, әнә шуннан шунда хәтле, аннары соң суғабыз. Үзенең ыстаны була торған ыйы. Баwлары бөтөн нәрсәсе әзер ийе аныћ. Бәк күб аның эше. Әwәле без хыйалландығ инде аның белә, иптәш. Абыйлар бар ыйы, бер күлмәге белә бер ыштаны бер чиләк була торғаныйы. Әле аны суққачыннан һәйбәтләп менә китәсе қыз бит инде, ағарттық, аны көллө суға салып, қайнатып, сары суwын чыгардық та. Аннары суң җәйгә чыға башлағачыннан йаз җитүгә, ындыр табағына алып җәйдек. Наруш суға манычтық та җәйдек, суға манычтық та җәйдек. Аның җебен дә ағартқаладығ әле сиңа. Киләп җепләрне түбәгә җәйеп җеб ағарттық ақ нәрсә суғу өчөн. Аннары инде киндерне суққачыннан ағарттық. Оло кисмәкне чығарып қуйдық та су тутырып, шуңа кипкән сайын манычтық та җәйдек, манычтық та җәйдек. Ул аппақ булды. Аның эше бәк күб ийе, сеңем, хәзер генә асат ул. Аннан китәсе қыз ашаwлық сукты, сөлгө сукты, җәймә сукты име. Әнә шул ағартқанынннан чолғаw суктық. Киндерне ағарттық та шуңа чолғаw эшләделәр. Минеке дә бар ийе кийәwгә барғанда чолғаwларым. Айақ баш чолғаw да эшләдек, аннары айақ башы да бар ийе моноң хәтле генә. Аның чолғаwы моның хәтлерәк булыр ийе, айақ башы тағын моноң хәтле генә буладыр ийе. Менә қунычына чормағаннан суң башына чормарға тағы кирәк бит, башыныкы айрым ийе.

Сөйләүче: Хәкимова Сылубикә, 68 яшь. Татарстанның

Саба районы, Алан Елга (Яңа Шекше) авылы. Эксп., 1973 ел.



# Гатауллина Разыя Вәли кызы

**(.....1910 - 29.09.1981)**

## Әнием турында истәлекләр

...Хәтирәләр, хәтирәләр...

Әнием турында истәлекләр язуны сорап шалтырату алгач, башыма килгән иң беренче уй, бу изге проектны уйлап табучылар, шул проект өстендә эшләүчеләргә чиксез рәхмәт хисләре булды. Ирләре сугыш кырында илебез азатлыгы өчен көрәшкәндә, ачлык-ялангачлык белән көрәшеп тылда эшләгән, йорт-җирләрен бөтен килеш, бабаларын ач үлемнән саклап калган, көндезләрен колхозларда, завод-фабрикаларда, фәнни институтларда эшләгән, ә төннәрен фронтка җибәрергә бияләй-носкилар бәйләгән, чабата үргән, үзе ач булса да, актык өшегән бәрәңгесен балаларына ашатып, үлемнән алып калган әниләр турында бик кирәк мондый истәлекләр. Менә болар башыма килгән беренче уем. Ә икенче уем: нигә әти-әни исән вакытта күбрәк сорашмадым икән, нигә язып калмаганмын икән,-дигән уйлар. Яшь вакытта аңламыйсың бит, әти-әни мәңге яшәр кебек тоела...

Минем әнием Гатауллина Разыя Вәли кызы 1910 елда Алан-Елга авылында дөньяга килә. Әниемнең әтисе Вәли бабаем җәен иген игеп, терлек асрап көн күрсә, кыш айларында үзенең “Зингер” машинасын асып, Оренбург, Астрахань якларына барып, хәлле кешеләргә тегү теккән. “Бик пөхтә, чибәр, уңган кеше иде бабагыз”-дип сөйли иде әнием. Әниемнең уңган, тырыш булуы да, тегәргә осталыгы да бабаемнан килгәндер. Әбием дә уңган хуҗабикә булган.

Утызынчы елларның авырлыклары минем әнием гаиләсен дә урап узмаган. Халык, башына төшкән заман, чор авырлыкларын бергә күтәргәннәр. Авыл халкы, бәхет эзләп, семья-семья ерак көнчыгышка языльп китә башлагач, мондагы тормышны таркатып, мал-туарларны алып, ни булса да халык белән бергә булыр дип, товар поездына утырып алар да ерак көнчыгышка киткәннәр. Урман кисү эшендә эшләп яңа тормыш башлаганнар. Чит җирләрдә тормыш итү авыр булган, сагыну да булгандыр, башка гаиләләр кайта башлагач алар да кире әйләнеп кайтканнар.

Әнием шундый матур, тату гаиләдә бердән-бер бала булып үссә дә, 1934 елда, әтием Гатаулла улы Хәкимулла белән кушылып, унберенче кеше булып, ишле семьяга килен булып төшә. Гатаулла бабай нык тормышлы, эшчән кеше булган, иген иккән, күп итеп маллар асраган. Мал эчертергә су күп кирәк булгач, малларны су буена куып алып төшеп эчерткәннәр. Җәен эш күп булганда, үзләре генә җитешә алмаганнар, сезонлы эшчеләр яллаганнар. Бабай эшкә бик дуамал кеше булган. Нык тормышлы булу өчен күп эшләргә кирәк булган шул. Бабай үзе дә 3-4 сәгать кенә йоклаган, балаларына да тынгы бирмәгән, гел эштә булганнар. Шундый зур тырышлык белән төзегән хуҗалыкны дәвер чире-раскулачивание башлангач таркатканнар. Башта мал-туарны, аннан йортны сүтеп алып киткәннәр, келәтнең түбәсен сүтеп алганнар Себергә сөрелүдән бабам гаиләсе котылып калган. Тырыш бабам, түбәсез келәттә яшәп балалары белән бергә яңа хуҗалык төзегән.

Әтием сугышка киткәндә, әниемә нибары 31 яшь булган. Берсеннән-берсе кечкенә өч бала белән утырып калган әнием: олы апама 6 яшь, уртанчысына 3 яшь, кечкенә апама 1 яшьтә булмаган. Кечкенә балаларын калдырып әнием көнне төнгә ялгап эшләгән: окоп казырга да йөргән, урман кисәргә дә, кырда да эшләгән. Күбрәк атлы эштә эшләгән ул. Ашлык, печән ташыган, кыш көннәре урманнан утын да ташыган. Әтиемнән калган кайры тунны киеп, аның каешын биленә буып куйган ябык, бәләкәй әниемнән, “бу тун эчендә кеше бармы соң?”- дип көлә торган булганнар. Кышны яз алыштырган, ә язын әнием авыл хатыннары белән бергә, өсләренә, аякларына юклы-барлы сәләмәләрен киеп Арчага симәнә ашлыгына йөргән. Шул ерак арадан ашлыкны күтәреп алып кайтканнар. “Үзем ач булсам да, язгы суны ерып кайта-кайта юешләнгән, туңган аякларым берни сизмәскә әйләнеп егылырдай хәлгә килсәм дә, өйдәге мине көтүче ач балалар көч бирә иде, кайтыр юлда маяк булып алты күз тора иде” – дип сөйли иде әнием. Аларны ашатырга язын көздән кырда калган өшегән бәрәңгеләр җыйганнар, алабутадан ипи пешергәннәр. Балалар туйганчы бер умач ашы ашасыннар дип әнием бабаемның “Зингер” машинасын да 4 кг арыш онына алыштырган. Ләкин ул озакка җитмәгән шул. Балаларны, булганын ашатып йокларга салгач, әнием төннәрен чабата үргән, бәйләү бәйләгән, иске-москыдан балаларга кул белән киемнәр теккән. Әниемнең язмышы тылда эшләгән бик күп хатын-кызлар язмышына охшаган. Күбесенең ирләре сугыштан әйләнеп кайтмаган. Ә минем әтием бик күп авырлыклар күрсә дә, ярты сәламәтлеген калдырса да, исән килеш әйләнеп кайткан. Әниемнең сугыш вакытында үзен аямыйча эшләве, күргән газаплары, авырлыклары, өч баланы исән-сау килеш саклап калуы, коры сөяккә калган гәүдәсе белән уфалла арбасы, тормыш арбасы тартулары эзсез генә үтеп китмәгән. Әтием кайтуга, ул урын өстенә егылган.

Селкенә дә алмыйча тугыз ай урын өстендә яткан. Әтиемнең мәхәббәте, бала караган кебек аны тәрбияләве әниемне яңадан аякка бастырган. Сугыштан соң без тагын өч бала: ике абыем һәм мин дөньяга килгәнбез. Сугыштан соңгы авыр елларда безне үстерү дә җиңел булмагандыр. Әнием сугыштан соң да колхозда эшләгән, башта атлар караган, аннары яшелчә бакчасында эшләгән. Өйдә дә яшелчә, җиләк-җимеш бакчасы ясадылар. Элек татар авылларында юк иде бит андый бакчалар. Минем әти-әнием Казаннан алып кайтып 15 төп алмагач, карлыган, крыжовник, җиләкләр утырттылар. Күп кешеләргә үсентеләр биреп бакчалы иттеләр. Кыяр, помидор, гөмбәләрне зур бочкаларга тозлый торган иде әнием. Оныкларын бик яратып үстерде.


Күп авырлыклар күрсә дә, күңеле керләнмәгән изге күңелле, тыйнак, унган әниемне искә төшергәндә, ил өстенә төшкән авырлыкны үз җилкәләрендә күтәргән – тылда эшләгән барлык хатын-кызларга карата соклану, горурлык, рәхмәт хисләре күңелемдә!!! Бу истәлекләр алар рухына дога булып барсын.

Гатауллина Разыяның кызы, Самирханова Илдария

Хәким кызы кулъязмасыннан.

Казан шәһәре





# Галимов Габделбадик Галим улы

**(3.02.1932 –9.07.2011)**

Галимов Габделбадик Галим улы 1932 елның 3 февралендә Саба районы Шекше авылында дөньяга килә. Әтисе Гатиятов Галим Гатият улы, әнисе Гатиятова Фатиха Хәсән кызы.

Гаиләдә өч бертуган: олысы Габделбадик, энесе Рәшит һәм сеңлесе Фәйнә үсәләр. Габделбадик җиде яшьтә Шекше мәктәбенә укырга керә. Укый башлауга, Бөек Ватан сугышы башлана, укулары сирәгәя, тылда эшләргә эшче көчләр кирәк була башлый. Габделбадик көче җиткән эшләрдә катнаша. Күп авырлыкларны җиңәргә туры килә. 1948 елда колхозга керә, фермада төрле эшләрдә эшли, урман кисүдә хезмәт куя.

Җәмәгате Галимова Зәйтүнә белән биш бала тәрбияләп үстерәләр. Хезмәтләрен хөрмәтләп, 1998 елда “Хезмәт ветераны” исеменә лаек була. 1995 елда “Тыл ветераны” медале бирелә. Сугышта җиңүнең 50, 55, 60 еллыкларга юбилей медальләре белән бүләкләнә.

1992 елда лаеклы ялга чыга. 2011 елның 9 июлендә вафат була, Шекше зиратына җирләнә.



Улы Галимов Ринат кулъязмасыннан.

18.04.2016 ел



# Нигъмәтжанова Бибинур Әлмөхәммәт кызы

**(7.03.1925 –4.04.2003)**

Минем әбием Нигъмәтжанова Бибинур Әлмөхәммәт кызы 1925 нче елнын 7 мартында Саба районы Алан-Елга авылында колхозчы гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә.

1933 елда Алан-Елга урта мәктәбенә укырга керә. Анда 7 ел белем алып ,1940 елда мәктәпне бетерә. Әбием жыр-моңга гашыйк бала булып үсә. Авылыбызда куелган театрларда яратып катнаша.

Әбием үзенең хезмәт юлын сугыш башланган елларда урманда кортчылыкта башлап жибәрә

1945 нче елда сугышта бер аягын өздереп кайткан сугыш инвалиды Нигъмәтжанов Шәрипжан Нигъмәтжан улы белән тормыш корып жибәрәләр. Алар 9 балага гомер бирәләр, хәзерге вакытта 2 баласы гүр ияләре. Бабаем белән 44 ел гомер итәләр.

.



Әбием сугыштан соң үзенен хезмәт юлын колхозда төрле эш башкаручы булып эшли. 1975 нче елда әбием лаеклы ялга чыга. Гомеренең ахыргы көннәренә кадәр әбием улы Рамил килене Фалиянур гаиләсендә тәрбияләнә.

2003 нче елнын 4 апрелендә 78 яшендә әбием бакыйлыкка күчә. Анын җәсады Алан-Елга зиратына күмелә.









Оныгы Нигъмәтҗанова Рания язмасы.



# Кашапова Миннегөл Габделгалим кызы

**(13.12.1913 –13.06.2005)**

Кашапова Миннегөл Габделгалим кызы Саба районы Сәрдә авылында 1913 елның 13 декабрендә дөньяга килә.

1936 елда шушы авыл егете Кашафетдин улы Сәхәб белән тормыш коралар, 6 бала үстерәләр. Сугышка кадәр олы уллары Зөфәр туа. Әткәйне сугышка алалар. Ул сугыштан кайткач ,2 малай,3 кызны дөньяга тудыра әнкәй.

“ Без тылда калган хатын-кызлар сугышның бөтен авырлыгын үз җилкәбездә күтәрдек. Колхозны алып бару бик авыр, яхшы атларны сугышка алып бетерделәр, калганнары ач, күтәрәмгә калды. Без аларны елый-елый бастырабыз, яшь кызлар өчен иң авыры шул иде”, – дип сөйли иде әнкәй. Сугыш чорында әнкәй өчен иң авыр вакыт була. Таяныр кешесе сугышта, ачлык, ялангачлык. Әнкәй төрле авыр эшләрдә эшли. Ул урман кисәргә барулары, ач килеш эшләүләре турында еш искә ала иде.

Басуда урак уру, ындыр табагында көлтә тыгып тору, нинди эш бар, шунда эшли, хезмәт куя.



Яшь чагында әнкәй мәчеттә дин сабаклары укырга йөри. Анда озак йөрми, мәчеткә ягарга  утын сорагач, әнисе җибәрми аны.

Куйган хезмәте өчен  “Хезмәт ветераны” исеменә лаек була. Бөек Җиңүнең юбилей медальләре белән күп бүләкләр, мактау кәгазьләре белән бүләкләнгән. Иптәшенең сугышта һәм тылда, үзенең тылда күрсәткән эшләре өчен горурланып яшәде

2005 нче елның 13 июнендә вафат була. Сәрдә авылы зиратына җирләнә

Истәлекләрне килене Гөлбану барлады.







# Яхина Тәкъмилә

**(......1891 - 27.05.1985)**

Д.Б.Рамазанова “Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре”, Казан, 2010

Китап 2004-2013 елларга Татарстан Республикасы дәњләт телләрен џәм Татарстан Республикасында бешка телләрне саклау, љйрәнњ џәм њстерњ буенча Татарстан Республикасы Дәњләт программасын њтәњ максатында нәшер ителә.

Сөйләүче: Яхина Тәкмилә, 80 яшьтә. Татарстанның Саба районы, Алан Елга (Яңа Шекше) авылы. Эксп., 1973.

Йегет йағыннан киләдер ийе димче, бер күрмәгән кешегә барас ийе бит шулай. Қилешсәләр аннары суң туй wәғәдәләре қуйып, шулай иттереп килешә торғаннар ийе. Димчегә бер йақын кешеңе җибәрәсең инде, ағайнымы, қәрдәшме шунда, белгән кешене йебәрәсең димчегә. Ул барып сөйләшә инде. Бирмәкче булсалар шунда мәһәрләрен, тартуларын, тарту акчаларын сөйләшеп, кирәк әйберләрен, сорасы әйберләрен сорап йебәрәләр инде. Тарту акчасы туй итәргә акча инде ул. Ақча бирә торғаннар ийе. Аннан суң қызға алалар инде, әйбер: сондоқ, қомған, күлмәклекләр, шәлләр, читек-қәwешләр. Сандыққа тутыралар да килешкәннән суң туйға қуйып, туйға киләләр инде эти-әнисе җегет җағыннан, шуннан туй итәләр, җегет җағыннан ағайнеләре килә инде шунда. Аннары суң туй итеп бер ике көннән суң кийәү әпкиләләр. Пар атлар җигеп, қыңғыраулар белә. Кийәү ике кич қуна, йә дүрт кич қуна йнде байырағы булса. Аннары шул атна кич сайын килеп йөри. Элек җийын бар ийе бит, җийынға килә торған ийе килен. Җийынға аптөшә торғаннар ийе киленне җийын атна кичендә. Қыңғыраулар тағып, пар атлар җигеп, килен йағыннан бер қыз утырып, қыз йанына тағы бер қыз утырып затырга килә. Шулай итеп төшерәләр инде киленне. Қодачалары килә инде шулай. Икенче арбаға малын төйәб аппара, түшәген, йастығын, мендәрләрен төйәб аппаралар. Кергәндә мендәргә бастыралар.



# Гибадуллина Асылбикә Шакирҗан кызы

**(14.02.1916 –1.04.2004)**

Безнең әниебез Гибадуллина Асылбикә 1916 елның 14 февралендә Саба районы Шекше авылында дүртенче бала булып дөньяга килә. 1932 елда 15 яшендә Казанга житен комбинаты ашханәсенә эшкә урнаша. Тулай торакта яши башлый һәм кичке мәктәптә укып 4 класс белем ала. 1939 елда авылга кайта һәм әтиебез Кәбир белән гаилә коралар. 1941 елда әтиебез сугышка китә. Әнигә сугыш вакытында төрле эшләр башкарырга туры килгән: бригадир вазифасын башкарган, урман кискән. Тормышлар нинди авыр булса да, әни белән әти биш кыз , бер малай тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә барыбыз да исән-саулар, бәхетле картлык кичерәбез.

Әниебез Асылбикә 2004 нче елның 1 апрелендә вафат була һәм Шекше зиратына җирләнелә.

Кызы Дамира кулъязмасыннан.

21.04.2016 ел

# Хафизова Фәхрибану Шәяхмәт кызы

**(…...1902 –10.03.1981)**

Минем бабамның әнисе Хафизова Фәхрибану Шәяхмәт кызы 1902 елда Шекше авылында туган. Аның 6 баласы булган. Сугыш вакытында ачлык кичергән. Ул үзе фермада эшләгән, басуда урак урган, дүрт чакрым ара йөргән. Аның ире Харис бу вакытта сугышта булган, бөтен авырлык аңа төшкән. Ул сарыкларны, бозауларны караган. Алар ире Харис белән 38 ел бергә яшәгәннәр. Фәхрибану әби 1981 нче елның 10 мартында вафат була. Шекше авылы зиратында җирләнгән.

Хафизов Ханиф абый сөйләгәннәрне оныгы Хафизова Зәринә язды, 6 класс

19.04.2016 ел



# Рахматуллина Бибигамилә Нигъматҗан кызы

**(15.04.1909 –13.12.1991)**

Рахматуллина Бибигамилә Нигъматҗан кызы 1909 елның 15 апрелендә Кукмара районы Каенсар авылында байлар семьясында туган. Саба районы Алан-Елга авылына 1930 елда Рахматуллин Салих Рахматулла улына хәлле гаиләгә килен булып килә. Монда өч бала таба. Әткәй сугышка 1941 елның июль аенда китә. Әнкәй дүрт бала белән кала. Иң олысына 15 яшь, иң кечесенә 1 яшь була.

Сугыш вакытында әнкәй колхозда нинди эш бар, барысын да эшли: урак уру, көлтә бәйләү, печән чабу, амбарда эшләү, фермада мал карау- бер эштән дә калмый ул. Шулай итеп кызлар үсә тора, урнаша бара, бер малай белән кала. Бик авырлыклар күрә-күрә гомер итә. Тормышлар җайланып, гомер үтә, ул 82 яшькә җитә. 1991 елның 13 декабрендә гүр иясе булды.



Төп йортта яшәүче килене Җәннәтнур кулъязмасыннан.

19.04.2016 ел



# Гөлсылу Кәлимуллина

**(....1930 - 6.08. 2010)**

Гөлсылу Кәлимуллина 1930 елда Саба районы Алан-Елга авылында туган. 7 класс белем алган. Колхозда эшләп, лаеклы ялга чыккан. 2010 нчы елның 6 августында вафат була һәм Алан-Елга зиратына җирләнелә.

Плугарь булып эшләгәндә
Иңләп-буйлап йөрдек басуны,
Тракторның радиаторы тишек булгач
Әйләнгән саен сала идек суны.
Чаналарга төяп тирес түктек
Тау ягындагы кырларга,
Бу нужалар тигез булды
Кечеләргә һәм дә зурларга.
Сугыш беткәнен ишеткәч,
Авыл халкының йөзе яктырды.
Җимерекләрне төзер вакыт җитте
Ватан безне шуңа чакырды.
Көзен урман кисеп кайтсак,
Кышын төядек вагонга,
Яшь чакта без бер дә арымый идек
Алабута ипие “тәмле ”булганга.
Ялган сүзләр түгел, заманы үзе шаһит
Нигә бүген моны дәшмик ди.
Мастерскоен, подвалын, күперен салдык
Истәлеге итеп яшьлекнең
Колхозыбызга нинди наряд килсә,
Эшләп, үтәп кайттык барсын да.
Аяк өстен йөреп, эшләп ялга чыктык
Йөзебез ак Ватан каршында.

# Онытылмас ул еллар.

Безнең яшүсмер чагыбыз
Туры килде кырыс елларга,
Герман сугыш башлап җәзалады
Өлгермәдек үсеп буйга да
Сугыш чоры балалары
Ятим үсте, иркәлекне күрмәдек,
“Кызым”,- дигән назлы сүзне
Ишетмәде, белмәде.
Сугыш алды кулдан тартып
Ипине дә, балачакны да,
Рәхәт күреп үсмәдек без
Тары бөртеге чаклы да.
Туйганчы йокы тимәде,
Сәгать өчтә үк тордык.
Карт-корылар, бала-чага
Чәчтек, урдык, суктырдык,
Язгы чәчү өчен симәнәне
Ерак авылдн алып кайттык без,
Ат шикелле кышын чана белән,
Җәен арбага җигелеп тарттык без.
Ул сугышны һәркем көрәшеп җинде
Солдат ашамыйча җиңәме?
Мәңге онытмыйк, ипекәйне урак белән
Җыйган әби, әни, апа, җиңгәне.
Норма тулса, ипи каба идек,
Яңа житкәч ,яңа арыштан
Кыш көнендә урак эше тәмам була
Ачлык башлана иде яңа баштан.

01.01.1930 ел



## Авылым хәзинәләре

Туып-үскән авылымның-
Исеме Алан-Елга,
Борынгылар урнашканда
Урманлык булган монда.
Иске урамны аерып
Елга ага киң түгел,
Авылыбыз гүзәллеге
Башка авылдан ким түгел
Авылыбыз бик күңеле
Аланлы да елгалы
Шуңа күрә авылыбызны
Ташлап китеп булмады.
Җәй көнендә, тау битендә
Кызарып пешә җир җиләк,
Яшьләребез бик тырышалар
Кызларыбыз да зирәк
Тау астында салкын чишмә
Камышлык яннарында
Таң алдыннан кошлар сайрый
Бөдрә талларында.
Мишә буена тезелгән
Тупыл, зирәк һәм талы,
Гомер узды, яшь вакытлар
Сагынып сөйләргә калды
Кызларыбыз сыер сава,
Ир-ат икмәк үстерә.
Өйдә калган әбиебез
Тәмле ашлар пешерә.
Яшьләргә әйтер сүзем шул:
Авылның кадерен белегез,
Үстергән икмәкләрегезнең
Иминлеген күрегез!

## Гөлсәрия бәете

“Кызым ни хәлең бар?” – дигәч,
“Рафаэль авырта ла”- диде.
Үзенең авыруларын
Санга сукмады инде.
Бик вакытсыз киттең балам
Өзелә үзәккәем
Валгасри укып кына
Басыла йөрәккәем
Еллар тулып узды балам
Ник бер кайтып китмисең
Төшләремә кереп
Ник бер сүз генә әйтмисең.
Кулыңнан эш китмәде
Кирәк ди- ди
Дөнья күргән
Бердә рәхәт күрмичә.
Яшьлегең белән эшләдең
Армадың да талмадың
Балаларыңнан игелек
Үзен күрә алмадың
Башымдагы яулыгымның
Бизәген кояш алды
Егерме ел тырышканың
Барсы да кешегә  калды
Иптәшләрең эштән кайта
Иртәнге җиде тулгач
Күзләремнән яшь тәгәри
Син янымда булмагач
Бигрәк сабыр булдың
Шул, бер генә сүз әйтмәдең
Эч серләреңне бушатып
Һич тынычлап китмәдең
Балаларың укып, эшләп йөри
Барысы да исән әле
Догаларым кабул булып
Тынычлап йокла яме.
Шигырь сыман итеп
Хатлар яздым сиңа
Юксынулар,
Катыш сагышлар
Адресын белмим,
Кайда салыйм
Әйтче Раппым, Аллам
Кайда торалар.



# Шарифуллин Хатмулла Шарифулла улы

**(10.06.1929 -30.01.2006)**

Шарифуллин Хатмулла Шарифулла улы 1929 елның 10 июнендә эшче гаиләсендә бишенче төпчек ул булып дөньяга килә. Әтисе Шарифулла сугышка алыну сәбәпле, аларның балачаклары авыр була. Ул армия сафларында биш ел хезмәт иттем дип искә ала иде. Хезмәт итеп туган якларына кайткач, Сәрдә авылы кызы Файзрахманова Сәгъдия белән гаилә корып, биш кыз тәрбияләп үстерәләр. Хезмәт юлын ул авылларда сөт җыеп башлый. Аннары 1965-1980 елларда авыл халкына газ балоны ташып хезмәт күрсәтте. 1989 елда лаеклы ялга чыкты. 2006 елның 30 январенда бакыйлыкка күчте һәм Алан –Елга зиратына җирләнде.

Оныгы Хаертдинова Сирена кульязмасы



# Хаертдинова Миңнебикә Нигъматҗан кызы

**(30.10.1910 –1.04.1999)**

Хаертдинова Миңнебикә Нигъматҗан кызы 1910 елның 30 октябрендә Алан-Елга авылында туа. Сәрдә авылы егете Фәйзрахманга кияүгә чыга. Аларның биш балалары туа. Бер уллары яшьтән үлә. Алар Фәйзрахман белән бары тугыз ел яшәп калалар. Сугышка киткән Фәйзрахман кире әйләнеп кайтмый. Миңнебикә яшьтән колхозда хезмәт итә.

1999 елның 16 апрелендә бакыйлыкка күчә.

Хаертдинова Сирена



# Валиева Миннегөл Валиевна

**(15.03.1925 –27.10.1999)**

Валиева Миннегөл Валиевна Саба районы Шекше авылында 1925 елның 15 мартында беренче бала булып дөньяга килә.



Менә шуннан башлана инде аңа тормышның ачысын-төчесен татырга. Сугыш башланганда , алар 7 бала калалар, бөтен авырлык олы балага төшә. Ул фермага аяк атлый. Сәрдәдә сыер фермасында сыер сава, сарык, тавык, дуңгыз- бозау барысын да карый ул. Әле ул коммунист та була, аның мактау кәгазләре бик күп. Олыгая башлагач, мәктәпкә җыештыручы булып эшкә урнаша. Ялгызы ике бала тәрбияләп үстерә. Аның тормыш юлы бик авыр һәм катлаулы үтә.


1999 елның 27 октябрендә 74 яшьтә дөньядан китә. Шекше зиратына җирләнгән.

Миннегөл апа кызы Зәлилә кулъязмасы

24.04.2016



Миннегөл апа хезмәттәше
Габделхакова  Рәзифә белән эш вакытында



# Галимуллина Нурсабах Шәвәли кызы

**( ....1912 - 30.05.1983)**

Минем әнием Галимуллина Нурсабах Шәвәли кызы 1912 елның январь аенда Алан-Елга авылында колхозчы семьясында беренче бала булып дөньяга килә. Әтисе Төхфәтулла улы Шәвәли, әнисе Идрис кызы Шәмсебанат була. Әнисе бик яшьтән үлү сәбәпле, әни үги ана белән үсә. Гаиләдә өлкән бала булу сәбәпле әнигә белем алу мөмкинлеге булмый, ул я дин сабагы, я латинча белем алу бәхетенә ирешә алмый. Шулай да ул өйдә хатын-кыз эшләренә бик тиз өйрәнә һәм бик тырыш эш сөючән бала булып үсә.

Әтием Галимуллин Кәрим Галимулла улы белән (ул да шушы ук авылда 1911 елның декабрь аенда туган) танышып, аның белән тормыш коралар. Әтием дә бик тырыш, белемле(заманына күрә)гарәпчә, латинча һәм кириллицаны да белә. Яшьтән үк хисапчы, бригадир, соңыннан колхоз рәисе булып эшли. Бөек Ватан Сугышына “Тельман” исемендәге колхоз рәисе булып эшләгән вакытында алына һәм кире әйләнеп кайту бәхетенә ирешә алмый. Рота командиры, соңыннан майор исемнәре алып, II дәрәҗә Кызыл Йолдыз, I дәрәҗә Ватан Ордены һәм бик күп медальләр алып, 1945 елның 5 февралендә Герман җирендә ятып кала.

Әнием аны гомер буе сагынып көтеп, бер мине тәрбияләп үстерде. Әнием гомер буе колхозда тырыш хезмәт куйды. Урак уру, печән чабу һәм башка эшләрдә гел алдынгылар рәтендә йөрде. Бирелгән нормаларны артырып үтәп, мактау такталарында булды. Ул вакытта тормышлар бик авыр, ягарга-ашарга юк, бөтен авыр эш хатын-кыз өстендә, кул көче белән башкарыла иде. Еракка барып урман кисүләр, окоп казулар, вагон төяүләр, симәнә орлыкларын җилкәгә асып ерак авыллардан алып кайтулар. Малга ашату өчен печәннәрне баш түбәсенә көлтәләп куеп ташулар һ.б. авыр эшләр барысы да кул хезмәте белән башкарыла иде. Сугыш чорында “Ирләребез исән-сау дошманны җиңеп кайтсын өчен”,-дип тырышсалар, сугыштан соң илне күтәрү өчен тырыш хезмәтләрен куйдылар.

Әнием шушы авылда яшәп, 1983 елның 30 маенда вафат булды. Алан-Елга зиратына җирләнде.

Кызы Ахатова Нурия апа кулъязмасыннан.

24.04.2016 ел



# Корбанова Миңнебикә Нурулла кызы

**(16.06.1903 –18.12.1988)**

Корбанова Миңнебикә Нурулла кызы 1903 елның 16 июнендә Алан-Елга авылында туган. Фермада эшләгән. 1926 елда Тимершык авылына Габделвәли исемле егеткә кияүгә чыккан. Хезмәтен анда да фермада дәвам иткән, сарыклар караган. Өч бала тәрбияләгән. Олы кызы Миңнур 1928 елда туган, улы Ханиф 1931 елгы, кече кызы Асия 1941 елгы. Ул бүгенге көндә Иләбәр авылында яши. Миңнебикә әби сугышта Габделвәли бабайны югалткач, 1947 елда туган авылына әйләнеп кайта. Гомер буе фермада эшләп пенсиягә чыга. Килене, улы белән яшәп, оныклар үстерешә. Авылда укымышлы абыстай булып, коръәннәр укып йөри.

1988 елның 18 декабрендә вафат була. Алан-Елга авылы зиратына җирләнә.

Оныгы Зөлфия, 24.04.2016 ел

# Хаернасова Гайшәбикә Ислам кызы

**(...1907 –6.05.1979)**

Хаернасова Гайшәбикә Ислам кызы 1907 елда Тимершык авылында туган. Яше җиткәч авылында кая кушсалар шунда эшләгән. 1935 елда Алан-Елга авылына Хаҗи исемле егеткә кияүгә чыккан. Өч ир бала табып үстергән. Беренче баласы Хаернасов Миннехан 1938 елгы, икенчесе Хаернасов Хәмит 1940 елгы, өченчесе Хаернасов Мидехәт 1943 елгы. Алан-Елгага килгәч тә колхозда эшләгән. Ире Хаҗи 1943 елда сугышка китеп, яраланып 1945 елда кайткан һәм 1946 елда вафат булган. Гайшә әби улы Хәмит гаиләсендә яшәп 1979 елның 6 маенда вафат булган.

Улы Хәмит, килене Хәнүзә сөйләгәннәрдән.

# Хисамова Әлфинур Галиәхмәт кызы



1926 нчы елның 17 январендә туган.

Әлфинур апа мәктәп бакчасында үзенең хезмәттәше Габделхакова Рәзифә белән





Сулдан: Әлфинур апа үзенең хезмәттәшләре Габделхакова Рәзифә, Вәлиева Миннегөл, Аглиуллина Рәхимә белән.

# Шаяхметова Разыя Хаертдин кызы

**(1908 –8.01.1987)**

Шаяхметова Разыя Хаертдин кызы 1908 нче елда Шекше авылында туа , 4 кыз һәм бер малай булып буй житәләр. Әбинең туган нигезе Хайретдинов Ризван абыйлар йорты. Ризван абый әбинең энесенең малае. Разыя әбием гомере буе ямьле Мишә буенда гомер кичерә. 1930 нчы елда Алан - Елга авылынын Шәяхмәтләр гаиләсенә килен булып төшә, Хужи бабай белән 6 бала тәрбияләп үстерәләр. Яшьлеге колхозлашу чорларына туры килгәнлектән , бригадир нинди эш куша барын да эшләгән. Иртә яздан , кара көзг кадәр колхоз басуында булганнар. Әби бәрәнгене кыскыч белән кар арасыннан җыя идек, дип сөйләгәнен хәтерлим. Зиннур абый сөйләве буенча, хәзерге сыер фермалары урынында басу булган , уфалла арбасы белән ул этине басуга имезергә йөрткән. Ә анда колхозчыларга гел борчак боткасы пешерэ торган булганнар. Әбием Разыя 1987 елның 8 январендә вафат була һәм Алан—Елга зиратына җирләнелә.

Кукмарада яшәүче оныгы

Ахметзянова Ләйсән кулъязмасыннан.



# Гатауллина Махиасма Шэмсетдин кызы

**(......1907 - 16.09.1989)**

Гатауллина Махиасма Шәмсетдин кызы 1907 нче елда Саба районы Эзмә авылында туган. Өч бала тәрбияләгән Рәшит, Гөлбану, Рәйсә. Ире Сөнгатулла сугышта улеп калган. Үзе 1989 нчы елның 16 сентябрендә вафат булды һәм Алан –Елга зиратына җирләнде.



Фаваризова Рәлинә, 6 класс

# Зарипова Минниса Хәмидулла кызы

**(12.09.1910 –25.05.2002)**

Зарипова Миннисa Хәмидулла кызы- 1910 нчы елның 12 нче сентябрендә туган. Әтисе Хамидулла һәм әнисе Бибиниса гаиләсенә куаныч өстәп ,беренче бала булып дөньяга аваз салган. Әбиемнең тагын ике сеңлесе Мөнәвәрә белән Сәвия һәм бер энекәше Хөснулла туган. Үсеп буй җиткәч, Алан – Елга авылы егете Хафиз улы Гомәргә тормышка чыккан. Алар бик тату, нык гаилә булып яшәгәннәр. Бер – бер артлы балалары Гөлҗиһан, Нурҗиһан, Габдулла, минем әтием Нурайхан туган. Матур гына гомер иткәндә, сугыш башлана. Бабам Гомәрне 1941 елда сугышка алалар, шул ук елны ул сугышта хәбәрсез югала. Дүрт бала белән әбием тол кала.

Озак та тормый ,кызы Нурҗихан үлеп китә, 18 яшендә Габдулла атлы улы да гүр иясе була. Күргән хәсрәтләренә тешен кысып түзеп, аллага шөкер итеп, яши әбием.

“Тормышта нинди генә авырлыклар килсә дә сыерны бетермәдек, балаларым тук булсыннар, кешенекенә кызыкмасыннар дип яшәргә тырыштым,” - ди торган иде әбием.

Колхозда бер эшне дә сайламыйча хезмәт куя әбием. Сугыш вакытында ачлы- туклы килеш станциягә вагон төяргә, урман кисәргә, окоп казырга йөргән ул. “Өйгә кайтып җиткәнче чабатаның асты төшеп кала, аяклар өши,” - дип сөйли торган иде.Мичкә салып пешергән икмәкне, йомыркаларны, сөтне, язган майларны балалар авызыннан өзеп, салымга җыеп алып чыгып киткәндә ,үзәкләр өзелә иде дип сөйләгәне хәтердә.

Ике газиз баласының да толлык ачысын күрергә насыйп була аңа: кызы Гөлҗиһан 28 яшендә ике бала белән, улы Нурайхан 45 яшендә берсеннән – берсе кечкенә дүрт бала белән тол калалар. Улының балаларын, ягъни безне үстерү, кеше итү өчен, әбием бар көчен кызганмыйча тырышты. Бүгенге көнебез өчен аларга мең рәхмәт!! Олыгыйган көнендә әбием ак әби –авылыбызның абыстае булып яшәде. Зиһенле, зирәк,  камил акыллы әбием янына ярдәм, киңәш сорап тирә-күрше авыллардан да киләләр иде. Кешеләргә гел ярдәм итеп, үзе дә кадер – хөрмәттә гомер кичерде әбием.

Әбием ,бакый дөнья турында сүз чыкканда , җәй көне чәчәкле, көз көне моңсу, кыш көне суык, яз көне ямьле кайчан гына китәсе инде дия торган иде. 2002 нче елның 25 нче маенда 91 яшендә әбием вафат булды. Урының җәннәттә булсын, Әбием!!!

Шәмәрдәндә яшәүче Мөхәммәтҗанова Чулпан кулъязмасыннан.



# Вафин Гаптелкаюм Вафа улы

**(1.02.1929 –5.08.1999)**

Вафин Гаптелкаюм Вафа улы 1929 елның 1 февралендә туган. Аңа 12 яшь тулган вакытта сугыш башлана. Сугыш вакытында алар ат җигеп, Шәмәрдәндә, урман кисеп, агач чыгарырга йөриләр. Яз көне ат белән чәчүлек орлык ташыйлар. Аны шул елларда эшләгәне өчен “За доблестный труд”дигән медаль белән бүләклиләр.

Каюм бабай гомере буе туган авылында “Ирек” колхозында эшли. “Хезмәт ветераны” дигән исемгә лаек була.

1954 елда Арча районы кызы Тәскирә белән кавышалар. Дүрт малай, ике кыз тәрбияләп үстерәләр.

1989 елда лаеклы ялга чыга. 1999 елның 5 августында вафат була. Алан-Елга авылы зиратына җирләнә.

Сафина Айсинә 9 класс, Алинә 4 класс





# Галимҗанова Нәсимә Гайфулла кызы

**(9.12.1913 –4.08.1994)**

Галимҗанова Нәсимә Гайфулла кызы 1913 елның 9 декабрендә туган. Атасы Рахматуллин Гайфулла. Анасы: Рахматуллина Мәргүбә Сафиулла кызы.

1932 елның 26 июлендә Галимзянов Рахимҗан Галимҗан улына кияүгә чыккан. Балалары: Рахматуллина Тәслимә 1937 елгы, Галимҗанов Ильяс 1940 елгы.

Сугыш вакытында окоп казуларга һәм башка төрле эшләргә йөргән. Пенсиягә чыкканчы ,дуңгыз фермасында мал караучы булып эшләгән.

1994 елның 4 августында вафат булган, Алан-Елга авылы зиратына җирләнгән.

Оныгы Алмаз язмасы, 24.04.2016 ел

# Рахматуллина Гыйлминур Җиһанша кызы

**(1.01.1900 –1.01.1980**

Рахматуллина Гыйлминур Җиһанша кызы 1900 елнаң 1 январь Арча районы Сикертән авылында туган. Алар алты бала булганнар. Иң олы бала Гильминур, Гафур, Шәкүр, Зәкия. Җиһанша бабай ат печүче, сөннәтче, итек басучы булган. Биш бала белән Җиһанша бабай Казахстанга, Полбагар шәһәренә китә. Булачак ире белән ул Казахстанда таныша. 1921 елга китеп, 1923 елда кайталар. Җиде атна җәяү кайталар. Шекшегә кайтып яшиләр. Җиде бала тәрбиялиләр. Өч балалары кечкенә вакытта ук үлә. 1938 елда өлкән апалары дары заводына китеп эшли. Уракны оста урган. Сыер фермасында сыер сауган. Сыер фермасы Сабантуй урынында була. Аннан окоп казырга җибәрәләр. Бер кыш буе анда окоп казый. Аягын өшетеп кайта. Амбарда биш ел тирәсе каравылчы булып эшли. Хезмәт ветераны исеменә лаек булды, пенсиягә чыкты.

1933 елны Алан-Елга Шәрифә белән Казанга съездга барган. Анда аларга бүләк итеп күлмәклек биргәннәр. Съездда “Коммунист ул нинди кеше?”-дигән сорауга, “Коммунист, пәйгамбәр шикелле кеше була,”дигән.

Сыер, кәҗә асраганнар. Әтисенең тегү машинасын сатып, сука алганнар.

1980 елның 1 январенда вафат була.

Кызы Идиятова Гәзизә сөйләгәннәрдән.

# Мирзекиева Миңнебикә Хәмит кызы

**(8.07.1932 –24.03.2015)**

Мирзекиева Миңнебикә Хәмит кызы 1932 елның 8 июлендә Саба районы Юлбат авылында туа. Балачак елларны урман кисеп, Шәмәрдәннән чана белән симәнә ташып үтә. Бәхет эзләп ,көчкә паспорт юнәлтеп, иптәш кызлары белән Мәскәүгә китә. Мәксәүдә дә аларны бәхетле тормыш көтеп тормый, салкын яшелчә подвалларында эшләп, аяклары, куллары өши. Шунда әти белән танышып, 1953 елда Шекшегә кайтып төпләнәләр. Аннан бөтен гомерен колхозда эшләп үткәрә. Башта тавыклар карый, аннан сарыклар, таналар, дуңгызлар карый. Кайда гына эшләсә дә, әни барлык эшләрен намус белән башкара. 41 ел стаж белән пенсиягә чыга.

2015 елныд 24 мартында якты дөньядан китеп ,Алан-Елга зиратында җирләнә.